КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 декабрь г.Казань № 1195

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни-массакүләм чаралар оештырганда һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне куллану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1125 нче карары белән расланган Мәдәни-массакүләм чаралар оештырганда һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне куллану турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни-массакүләм чаралар оештырганда һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне куллану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1125 нче карары белән расланган Мәдәни-массакүләм чаралар оештырганда һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне куллану турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрен кулланып, чаралар әзерләү һәм үткәрү турында нигезләмә»;

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Нигезләмә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен кулланып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм

Татарстан Республикасы оешмалары (алга таба – оештыручылар) тарафыннан мәдәни-массакүләм чаралар әзерләү һәм үткәрү тәртибен билгели.»;

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бу Нигезләмә максатларында мәдәни-массакүләм чаралар төшенчәсе дип түбәндәгеләр аңлашыла:

мәдәни-иҗади (спектакльләр, концертлар, кино, лекторийлар, шигъри митинглар, перфоманслар (заманча сәнгатьне күрсәтү формасы), шул исәптән ачык һавада үткәрелә торган фестивальләр);

күргәзмә-экскурсия (күргәзмәләр, экскурсияләр, экспозицияләр күрсәтү, музей форумнары);

халык бәйрәмнәре белән бәйле чаралар;

фестиваль-конкурс (конкурслар, олимпиадалар, фестивальләр, иҗади профильле сменалар);

фәнни һәм белем бирү (конференцияләр, белем бирү форумнары һәм семинарлар, «түгәрәк өстәлләр» утырышлары, симпозиумнар һәм башкалар);

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы оешмалары тарафыннан үткәрелә торган башка чаралар.»;

2.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Мәдәни-массакүләм чаралар эчтәлеген Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге сценарие компонентларын җәлеп итү юлы белән баету.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Мәдәни-массакүләм чаралар әзерләү

3.1. Мәдәни-массакүләм чаралар (халыкка мәгълүмати хезмәт күрсәтүне кертеп), чара төренә һәм катнашучылар контингентына карап, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә үткәрелә.

3.2. Мәдәни-массакүләм чараларның әзерлек этапларына түбәндәгеләр керә: сценарий язу, реклама, визуаль атрибутика әзерләү, видеоконтент булдыру.

3.3. Мәдәни-массакүләм чараларның әзерлек этаплары Татарстан Республикасы дәүләт телләрен куллануны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.4. Мәдәни-массакүләм чараларның визуаль атрибутикасы (шул исәптән полиграфия: буклетлар, чакыру билетлары, программалар һәм башка иярчен материаллар) Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерелә.

3.5. Мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү урыннарын бизәү Татарстан Республикасының ике дәүләт телен паритетлы нигездә куллануны исәпкә алып башкарыла.

3.6. Мәдәни-массакүләм чараның сценарие, чараның (милли мәдәният һәм тел белән бәйле) тематик юнәлешенә каршы килмәсә, Татарстан Республикасының ике дәүләт телен паритетлы нигездә куллануны исәпкә алып төзелә.

3.7. Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләре тупланып яшәгән урыннарда мәдәни-массакүләм чаралар үткәргән очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре белән беррәттән, җирле халык теле кулланыла.»;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

### «4. Мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү

4.1. Мәдәни-массакүләм чараларны мәгълүмати тәэмин итү (басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-коммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәре) Татарстан Республикасының ике дәүләт телен паритетлы нигездә куллануны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4.2. Мәдәни-массакүләм чараларны документлар белән тәэмин итү Татарстан Республикасының ике дәүләт телен паритетлы нигездә куллануны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4.3. Мәдәни-массакүләм чараларны алып бару (текст уку, шул исәптән сәламләү, саубуллашу, диктор белдерүләре һәм гомуми характердагы комментарийлар) Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә яки Татарстан Республикасында күпләп яшәүче халык вәкилләренең телләрендә гамәлгә ашырыла, әгәр дә бу мәдәни-массакүләм чараның (милли мәдәният һәм тел белән бәйле) тематик юнәлешенә каршы килмәсә.

4.4. Мәдәни-иҗади чараларны тел ягыннан тәэмин итү күрсәтелә торган сәнгать төрләре һәм жанрлары (опера, балет, драма спектакле, төрле башкару составлары өчен концерт һ.б.) нигезендә сәнгать, иҗади бурычлар белән тәңгәл килә. Чарада лекторның кереш сүзе һәм алып баручының комментарийлары, әгәр дә чараның (милли мәдәният һәм тел белән бәйле) тематик юнәлешенә каршы килмәсә, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә гамәлгә ашырыла.

4.5. Татарстан Республикасында рәсми делегацияләр һәм Россия төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән килгән мактаулы кунаклар катнашында үткәрелә торган мәдәни-массакүләм чараларның рәсми теле оештыручылар тарафыннан билгеләнә.

4.6. Мәдәни-массакүләм чараларны оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

үткәрелә торган мәдәни-массакүләм чараларны Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белүче кадрлар белән тәэмин итү;

тиешле тематик җыентыклар, сөйләүлекләр, сүзлекләр һәм башка методик әдәбият эшләүне һәм аларны бастырып чыгаруны гамәлгә ашырырга;

үз теләге белән, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен кулланып, мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү вакытында синхрон тәрҗемә итүне гамәлгә ашыру өчен җиһазлар кулланырга;

Татарстан Республикасының ике дәүләт телен белүче, инвалидларга хезмәт күрсәтү һәм озатып йөрү өчен җаваплы белгечләрне җәлеп итәргә.»;

5 бүлек үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин